**Республика Татарстан**
**Шарлиареминское сельское поселение Сармановского муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районының Шәрләрәмә авыл җирлеге**

---

**РЕШЕНИЕ**
**25 ноябрь 2021ел**

**КАРАР**
**№ 31**

**«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Шәрләрәмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында нигезләмәне яңа редакциядә раслау хакында» Сарман районының Шәрләрәмә авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242_17 статьясындагы 4 пунктының гамәлдә булуын туктатып тору хакында» 2021 елның 1 июлендәге 244-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,

1. 5 статьяның 9 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр өчен физик һәм юридик затлар тарафыннан акчалар түләү өчен кирәкле мәгълүматны, шулай ук Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары керемнәрен формалаштыру чыганаклары булган башка түләүләрне «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртип нигезендә дәүләт һәм муниципаль түләүләр турында дәүләт мәгълүмат системасына тапшыра, Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш;»

2. 5 статьяның 10 пунктындагы 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) җирлек бюджеты дефицитын финанслау чыганакларын түләү өчен бүлеп бирелгән ассигнованиеләрне куллануның, бюджетның бердәм счетындагы калган акчалар белән идарә итү операцияләреннән тыш, адреслылыгын һәм максатчан характерын тәэмин итә»;

3. 5 статьяның 11 пунктындагы 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) җирлек бюджеты дефицитын финанслау чыганакларының бюджетка керүнең тулылыгын һәм үз вакытында керүен, бюджетның бердәм счетында калган акчалар белән идарә итү операцияләреннән тыш, контрольдә тотуны гамәлгә ашыра;”;

Шәрләрәмә авыл җирлеге
башлыгы

Н.Н.Хужина